ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

# КАРАР

№ 51 02.06.2021 ел.

Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның уртача район нормасы турында

Крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдән башкару өчен милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең минималь күләмен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 статьясындагы 1 пункты нигезендә һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 40 статьясындагы 2 пункты нигезендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән барлыкка килә торган яңа җир кишәрлегенең минималь күләме нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре чикләрендә авыл хуҗалыгы җирләрен гражданнар милкенә түләүсез тапшыру нәтиҗәләр нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән гражданнар милкенә түләүсез тапшыруның уртача район нормасын 2,4 га күләмендә расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatar.ru урнаштырырга һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту агросәнәгать комплексы, җирдән файдалану һәм экология мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе К.К. Гилманов